РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» 11 2019 г. №293

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булып торган муниципаль контрактларны банк аша уздыру очракларын билгеләү турында

2013 елның 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге «Контрактларны банк аша уздыруны гамәлгә ашыру турында» 963 номерлы карарына ярашлы, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Предметы булып Ютазы муниципаль районы өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү торган муниципаль контрактларны банк аша уздыруны тәэмин итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларны банк аша уздыруны тәэмин итү турында"гы 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә, контрактларны банк аша уздыру Кагыйдәләренә ярашлы, түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе 200 млн. сумнан да ким булмаса, банк тарафыннан исәп-хисап мониторингын үткәрү кысаларында төзелә торган контрактны банк аша үткәрүне тәэмин итүгә карата;

1.2. банк аша уздыру белән контрактны тәэмин итүгә, банк тарафыннан үткәрелә торган контрактны үтәү кысаларында башкарыла торган исәп-хисап мониторингын уздыруга өстәп, банк тарафыннан кабул ителә торган башка хезмәтләр күрсәтүне күздә тотып, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче

(подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе 1 млрд. сумнан да ким булмаган күләмне тәшкил итсә.

Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

Н.Н. Шмуровец
2-71-12